**Югары Чура авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**22 гыйнвар, 2024 ел** **№ 3**

Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылында «Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Пчеловод авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары-Чура авыл җирлеге Уставының 20 статьясы нигезендә Югары-Чура авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 04 февраленә 16 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Пчеловод авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Пчеловод авылы, Центральная урамы, 24 нче йорт адресында урнашкан авыл клубында уздырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Пчеловод авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә Сез ризамы:

2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлеге Пчеловод авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган

затлардан; шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 4450 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Югары Чура авыл җирлеге
башлыгы В.Н. Андреев